МГЛАВА
МАЛЬБАГУШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Нефтяников, д30, с.Мальбагуш,
Азнакаевский муниципальный район 423330

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ МӘЛБАГЫШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ БАШЛЫГЫ

Нефтьчеләр ур., 30 нче йорт, Мәлбагыш
авылы, Азнакай муниципаль районы, 423330

Тел./факс(885592)3-77-90,3-77-91; E-mail:Malb.Azn@tatar.ru,

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«02» ноябрь 2020 ел № 4

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Түбән Якый торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Түбән Якый торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 13 ноябренә билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Түбән Якый торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 13 ноябрь 2020 ел 10.00 сәг.тән 11.00 сәг.кадәр;

- үткәрү урыны – Түбән Якый авылы, Кашапов ур. , 7 нче йорт адресы буенча урнашкан "Якый" кибете каршысында;

1.3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2020 елның 3 ноябреннән дә соңга калмыйча гражданнарга Мәлбагыш авылы, Нефтяниклар урамы, 30 нчы йорт адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитетында һәм Түбән Якый авылы, Кашапов урамы, 23 нчы йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын бирергә;

- Түбән Якый торак пунктында сайлау хокукына ия булган яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Түбән Якый торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш Мәлбагыш авыл җирлеге Түбән Якый торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Түбән Якый авылында юлларны кардан чистарту(килешү буенча түләү);

- җәйге чорда Түбән Якый авылында үлән чабу, территорияне җыештыру буенча хезмәтләр (килешү буенча эшләр өчен түләү, триммер өчен запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

- Түбән Якый авылында "Авыл бәйрәме" үткәрү (бүләк, сувенир продуктлар сатып алу);

- Түбән Якый авылында торак пункт исеме белән стелла әзерләү һәм урнаштыру;

- Түбән Якый авылы зират коймалары өчен материаллар сатып алу, зират коймалары ясау һәм урнаштыру;

« РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Мәлбагыш авылы, Нефтяниклар урамы, 30 нчы йорт адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитетында һәм Түбән Якый авылы, Кашапов урамы, 23 нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. урнаштырырга

4. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык: А.Й.Әхмәтшин